**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1449**
**03.03.2021**

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең
шәһәр һөнәри осталык конкурсын
әзерләү һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5596 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасы нигезендә, яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең кадрлар потенциалын саклау һәм үстерү, иҗади эшләүче шәхесләрне ачыклау һәм аларның эшчәнлеген стимуллаштыру, профессиональ һәм карьера үсешләрендә ярдәм күрсәтү, һөнәрнең абруен популярлаштыру һәм күтәрү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә 2021 елның март-апрелендә Яр Чаллы шәһәрендә яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсын (алга таба – конкурс) үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурс үткәрү буенча оештыру комитетын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә чыгымнарны финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 0707 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 60 000,00 (алтмыш мең) сум 00 тиен күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1449 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең
шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсы (алга таба – конкурс) әлеге өлкә хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм һөнәрләренең абруен арттыруга, Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт яшьләр сәясәтен инновацион үстерү һәм модернизацияләүгә юнәлдерелгән.

2. Конкурс яшьләр белән эшләү өкәсендәге казанышларны күрсәтү мәйданчыгы булып тора һәм Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясен билгели.

3. Конкурс тармакның кадрлар потенциалының һөнәри компетентлылыгын һәм осталыгын формалаштыру юлы белән яшьләр белән эшләүнең яңа сыйфат дәрәҗәсенә ирешүгә юнәлтелгән.

2 бүлек. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

4. Конкурсның максаты – Яр Чаллы шәһәрендә тармакның инновацион үсешен тәэмин итү өчен яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче талантлы җитәкчеләрне һәм белгечләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү.

5. Конкурсның бурычлары:

1) яшьләр сәясәте хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын, абруен һәм социаль статусын күтәрү;

2) яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең һөнәри әзерлеген, инновацион потенциалын һәм социаль статусын бәяләү һәм дәрәҗәсен күтәрү;

3) инновацион программалар һәм проектлар төзүне һәм тормышка ашыруны стимуллаштыру;

4) яшьләр сәясәте өлкәсендә үзләрен уңышлы лидерлар итеп күрсәткән талантлы яшь хезмәткәрләрне ачыклау, аларның алга таба профессиональ үсешенә ярдәм итү;

5) яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыру, шул исәптән кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эш тәҗрибәсе белән уртаклашу мәйданчыклары ясау;

6) яшьләр сәясәтен тормышка ашыру мәсьәләләренә җәмәгатьчелекнең һәм барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарының игътибарын арттыру.

3 бүлек. Конкурсны оештыручылар

6. Конкурсны оештыручылар булып торалар:

- Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе;

- «Заман» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе.

7. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

- заявкалар кабул итә;

- конкурс сынаулары үткәрүне оештыра;
- конкурска йомгак ясый.

4 бүлек. Конкурс номинацияләре

8. Әлеге нигезләмә нигезендә түбәндәге төп конкурс номинацияләре билгеләнә:
1) «Иң яхшы яшьләр сәясәте учреждениесе җитәкчесе»;
2) «Яшьләр сәясәте өлкәсенең иң яхшы яшь хезмәткәре»;
3) «Яшьләр сәясәте өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре».

5 бүлек. Конкурста катнашучылар

9. Конкурста катнашучылар булып тора:
- яшьләр сәясәте муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм белгечләре;
- Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе белгечләре.

6 бүлек. Конкурста катнашу өчен документлар һәм аларны тутыруга таләпләр

10. Конкурста катнашу өчен конкурсантлар түбәндәге документларны тапшыра:
1) әлеге нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча заявка;
2) конкурста катнашучының «Молодежь России» АМС автоматлаштырылган мәгълүмат системасында www.ais.fadm.gov.ru тутырылган заявкасы (системада теркәлү узмаган очракта алдан теркәлү узарга кирәк);
3) әлеге нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган форма буенча катнашучының резюмесы;
4) шәһәрдә яшьләр сәясәтен үстерүгә юнәлдерелгән авторлык программасы (проекты);
5) конкурста катнашучының портфолиосы.
11. Авторлык программалары (проектлары) юнәлешләренең исемлеге:
1) яшьләргә патриотик тәрбия бирү;
2) җәмәгать оешмалары һәм хәрәкәтләренә ярдәм күрсәтү һәм алар белән үзара эшчәнлек;
3) халыкара һәм регионара яшьләр эшчәнлегеен үстерү;
4) яшьләрне ирекле һәм волонтерлык эшчәнлегенә җәлеп итү;
5) яшьләрне сәламәт яшәү рәвеше һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү; яшьләр мохитендә куркынычсызлык культурасын популярлаштыру;
6) яшьләрне инновацион эшчәнлеккә һәм фәнни-техник иҗатка җәлеп итү;
7) яшьләрне массакүләм мәгълүмат чаралары (яшьләр медиасы) эшенә җәлеп итү;
8) социаль-куркыныч хәлдә булган яшьләр белән эшләү;
9) яшьләр үзидарәсен үстерү;
10) яшьләрнең профориентациясенә һәм карьера омтылышларына булышлык итү;
11) Россия тәңгәллеген, Россия милләтенең бердәмлеген формалаштыру, мәдәниятара һәм конфессияара диалогка булышлык итү;
12) яшьләрне иҗади эшчәнлеккә җәлеп итү;
13) дәүләтнең аерым яклавына мохтаҗ яшьләрне социализацияләү;
14) яшьләрдә традицион гаилә кыйммәтләрен формалаштыру;
15) яшьләр сәясәте өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм кабаттан әзерләүгә ярдәм итү;
16) балалар һәм яшьләрнең ялы һәм аларны сәламәтләндерү.
12. Шәһәрдә яшьләр сәясәтен үстерүгә юнәлдерелгән авторлык программасы (проекты) түбәндәге таләпләр нигезендә башкарылырга тиеш:
1) А4 форматындагы ак кәгазь битләре (китап ориентациясе);

2) Times New Roman шрифты, төсе - кара, үлчәме 14, гадәти, исемнәре – үлчәме 16, калын;

3) төп текстны тигезләү – киңлек буенча, абзац чигенеше – 1,5, исемнәрне тигезләү – уртада;

4) юллар арасындагы интервал – 1,5;

5) битләрнең номерлары – аста, уң якта (титул битендә бит саны куелмый);

6) кырлар: сул як – 30 мм, өстә, уң як– 20 мм.

Программа (проект) бер документ итеп (брошюра ясап) беркетелергә тиеш.

13. Авторлык программасының (проектының) структура элементлары:

1) әлеге нигезләмәгә 3 нче кушымтада каралган форма буенча титул бите;

2) эчтәлеге (программаның (проектның) төп пунктларының исеме, бит санын күрсәтеп);

3) кереш:

- программаның (проектның) актуальлеге;

- программаның (проектның) яңалыгы;

- программаның (проектның) юнәлешле булуы;

- әлеге программаның (проектның) гамәлдә булган программалардан (проектлардан) аерылып тора торган үзенчәлеге;

- программаның (проектның) максатчан аудиториясе – яше, катнашучыларның социаль статусы;

- программаның (проектның) максаты;

- программаның (проектның) бурычлары;

- программаны (проектны) тормышка ашыру сроклары;

- программаның (проектның) дәвамлылыгы;

- хәзерге вакытта программаны (проектны) тормышка ашыру стадиясе;

4) программаның (проектның) эчтәлеге һәм тормышка ашыру технологияләре (тормышка ашыру механизмы һәм этаплы планы);

5) программаны (проектны) ресурслар белән тәэмин итү (финанслар, кадрлар, материаль-техник h.б.);

6) мониторинг нәтиҗәләрен (әгәр программа (проект) тормышка ашырылса), көтелгән нәтиҗәләрне (тормышка ашыру планлаштырыла торган программалар (проектлар) өчен) күрсәтеп, программаны (проектны) анализлау һәм нәтиҗәлелек дәрәҗәсен бәяләү);

7) файдаланылган әдәбият исемлеге;

8) кушымталар (фотографияләр, нәтиҗәлелекне раслау h.б. – конкурста катнашучы теләге буенча).

14. Авторлык программаларын (проектларын) бәяләү критерийлары (0 дән 5 баллга кадәр):

1) структура һәм бизәлеш буенча таләпләргә туры килү;

2) программаның (проектның) дәүләт яшьләр сәясәте юнәлешенә туры килүе;

3) программаның (проектның) максатчан аудитория өчен актуальлеге, яңалыгы (гамәлдә булганнарыннан аерылып торуы);

4) программаның (проектның максатларын һәм бурычларын ачык итеп бирү);

5) программаны (проектны) бәян итү сыйфаты: тулылыгы, стиле, логикасы булу;

6) программаны (проектны) тормышка ашыру тәҗрибәсе булу;

7) программаның (проектның) кирәкле ресурслар белән тәэмин ителеше;

8) нәтиҗәләрен күрсәтеп, программаның нәтиҗәлелек дәрәҗәсенә анализ һәм бәяләмә булу;

9) нәтиҗәләрнең куелган бурычларга туры килүе;

10) программаның (проектның) нәтиҗәлелеген күзәтергә мөмкинлек бирә торган индикаторлар булу.

15. Конкурста катнашучының портфолиосына куела торган таләпләр:

1) титул бите (катнашучының Ф.И.А.и., эш урыны һәм вазыйфасы күрсәтелә);

2) автопортрет (конкурста катнашучының иҗади үзпрезентациясе, аның үзен профессионал һәм шәхес буларак күрүе). Күләме буенча зур булмаган, 4-6 биттән артмаган әсәр, анда конкурста катнашучының һөнәри эшчәнлеге һәм шәхесе белән бәйле фикерләре һәм хисләре чагыла. Фәлсәфи фикер йөртү, лирик әсәр, юмористик мәкалә һәм хәтта киләчәк темасына фантазияләр характерында булырга мөмкин. Ирекле формада үзеңнең үзенчәлекле һәм креатив булуыңны күрсәтергә кирәк, фотографияләр куярга мөмкин;

3) шәхси казанышларны күрсәтә торган материал (үзеңнең профессиональ эшчәнлегеңнең нәтиҗәләрен күрсәтү, конкурсантның казанышлары турында массакүләм-мәгълүмат чараларында мәкаләләр чыгу һ.б.);

4) портфолио файл папкасында бирелә, эчке бизәлеше автор теләге буенча ирекле формада.

16. Портфолионы бәяләү критерийлары (0 дән 3 баллга кадәр):

1) оригинальлек, автопортретны ясауга һәм аны бизәүгә иҗади якын килү;

2) автопортретны бәян итүнең сыйфаты: логика булу, стиль һәм бәян итү культурасы, грамоталы булу;

3) үзеңнең профессиональ позицияңне төгәл күзаллау;

4) конкурсантның шәхси сыйфатларын ачу;

5) портфолиода тәкъдим ителгән материалларның эчтәлекле һәм әһәмиятле булуы.

## 7 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм сроклары

17. Конкурс түбәндәге этаплардан тора:

1) читтән торып (заявкалар кабул итү һәм аларны карап тикшерү, материалларны оештыру комитеты тарафыннан карап тикшерү);

2) урында;

3) финал.

18. Конкурста катнашуга заявка һәм аңа теркәлгән материаллар 2021 елның 20 мартына кадәр «Заман» Яшьләр үзәге» МАУда түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы шәһәре, Цветочный бульвары, 1А (20/07А), 14 кабинет яки кабул итү бүлмәсе.

Элемтәгә керүче зат: Захарова Динара Айрат кызы (89510680077, эш телефоны 54-22-24).

19. Материаллар конкурсның оештыру комитеты тарафыннан 2021 елның 20 мартыннан 2021 елның 23 мартына кадәр карап тикшерелә.

20. Урындагы этап түбәндәге сынаулардан тора:

1) портфолио конкурсы;

2) Татарстан Республиксы дәүләт яшьләр сәясәтен белү буенча тест (баллар саны сорауларга дөрес җаваплар саны белән билгеләнә);

3) рольле уен – дебатлар.

21. Финал үз эченә ала:

1) конкурста катнашучының телдән чыгышы («Минем визит карточкам» үзпрезентациясе);

2) авторлык программасын (проектын) яклау.

22. «Минем визит карточкам» үзпрезентациягә карата таләпләр

«Минем визит карточкам» - конкурста катнашучының компьютер презентациясеннән яки видеороликтан файдаланып үз-үзен презентацияләве, ул конкурсантның үзен һәм һөнәри казанышларын, аның һөнәргә мөнәсәбәтен иҗади итеп тәкъдим итүе, ул конкурсантның эшен һәм үз-үзен профессиядә күзаллавын күрсәтә. Үзпрезентация конкурсант турында фикер формалаштыруга ярдәм итә. Материалны оригиналь һәм мавыктыргыч итеп бирергә тәкъдим ителә.

23. Компьютер презентациясенә техник таләпләр:

1) компьютер презентациясе Power Point программасында .ppt, .pptx киңәйтеп башкарылырга тиеш;

2) слайдларның минималь саны – 10;

3) беренче бит – титул бите, анда мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр булырга тиеш: катнашучының фамилиясе һәм исеме, учреждениенең тулы исеме, вазыйфасы;

4) дизайн – эргономик таләпләр: төсләрнең ярашуы, слайдта объектларның чикләнгән санда булуы, текстның төсе. Презентация бердәм стильдә булырга тиеш (төс, шрифт-үлчәм, язылыш, тигезләү).

24. Видеороликларга техник таләпләр:

1) видеоролик фильмнар ясау буенча теләсә нинди программада эшләнергә мөмкин;

2) беренче кадрда катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, эш урыны һәм вазыйфасы булырга тиеш;

3) видеороликның дәвамлылыгы 2 минуттан артык булмаска тиеш.

25. «Минем визит карточкам» үзпрезентациясен бәяләү критерийлары (0 дән 3 баллга кадәр):

1) бизәлеше һәм эчтәлеге буенча таләпләргә туры килүе;

2) теманы тулысынча ачу, материалның мәгълүматка бай булуы;

3) материалның бизәлешенә һәм тәкъдим ителүенә иҗади якын килү;

4) материалның эчтәлеге һәм тәкъдим итү формасы оригиналь булу, сюжет линиясенең динамикасы;

5) эшне башкару сыйфаты (композиция, төс чишелеше, бизәлешнең грамоталы булуы һәм пөхтәлеге).

26. Конкурста катнашучының телдән чыгышына куела торган таләпләр.

Үзпрезентациясен дә кертеп, конкурста катнашучы чыгышының вакыт регламенты – 5 минуттан артык түгел.

Конкурсантның халык алдында чыгыш ясау культурасы, аның сөйләме, үз-үзен тоту манерасы, тышкы кыяфәте бәяләнергә тиеш. Конкурста катнашучы гомуми һәм һөнәри культура һәм эрудицияне, үз позициясен төгәл һәм дөрес итеп күрсәтә белергә, бирелгән сорауларга адекват һәм эчтәлекле җавап бирергә, артистлык һәм коммуникатив сыйфатлар күрсәтергә тиеш.

27. Конкурста катнашучыларга ярдәмче төркем-командаларның катнашуы хуплана, финалда алар өчен блиц-сораштыру оештырылачак.

## 8 бүлек. Конкурска йомгак ясау

28. Конкурс сынауларында катнашу нәтиҗәләре буенча һәр номинациядә җиңүчеләр (катнашучылар, беренче урын алучылар) һәм призерлар (икенче һәм өченче урын алучы катнашучылар) билгеләнә.

29. Конкурста җиңүчеләр һәм призерлар конкурс сынауларын узу нәтиҗәсендә конкурсантлар җыйган баллар суммасы буенча оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә. Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

30. Конкурста җиңүчеләр һәм призерлар дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә.

31. Конкурста җиңүчеләр яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең республика һөнәри осталык конкурсында катнашу өчен җибәрелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсында катнашуга

гариза

______________________________________________

(тәкъдим итә торган оешма исеме)

______________________________________________

(проект (программа) исеме)

______________________________________________

номинация исеме

номинациясе буенча дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсында катнашу өчен
______________________________________________ җибәрә

(конкурсантның Ф.И.А.и., эш урыны, вазыйфасы)

Конкурс документларының составы:

______________________________________________

Тәкъдим итә торган оешма
җитәкчесе
М. У.

Яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең
шәһәр һөнәри осталык конкурсында катнашучының
резюмесы

| | | | |
|---|---|---|---|
| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | | | |
| Туган көне, ае, елы | | | |
| Туу урыны | | | |
| Өй адресы, телефон, e-mail | | | |
| Гаилә хәле | | | |
| Эш урыны, вазыйфасы | | | |
| Белеме | Белем бирү учреждениесенең тулы исеме, керү/тәмамлау датасы | | |
| | Факультет | | |
| | Белгечлеге | | |
| | Белгечлек | | |
| | Өстәмә белеме: курслар, стажировкасы (исемен күрсәтеп) (әһәмияте тәртибендә) | | |
| | Икенче югары белеме (белем бирү учреждениесенең тулы исеме, керү/тәмамлау датасы) | | |
| | Аспирантура, докторантура (белгечлеген күрсәтеп), керү/тәмамлау датасы | | |
| | Гыйльми дәрәҗәсе | | |
| Эш тәҗрибәсе | 00.00-00.00 (ел, ай) | Оешманың исеме (эшчәнлек өлкәсе) | |
| | | Вазыйфасы (яисә статусы) | |
| | Бурычлары (иң мөһим моментлар күрсәтелгән тулы исемлек) | | |
| | 00.00.00-00.00.00 (ел, ай) | Оешманың исеме (эшчәнлек өлкәсе) | |

| | | |
|---|---|---|
| | Вазыйфасы (яисә статусы) | |
| | Бурычлары (иң мөһим моментлар күрсәтелгән тулы исемлек) | |
| Тутыру датасы | | |
| Шәхси имзасы | | |

Яшьләр сәясәте өлкәсе
хезмәткәрләренең шәһәр
һөнәри осталык конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Конкурста катнашучының авторлык программасы (проекты) титул бите үрнәге

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең
шәһәр һөнәри осталык конкурсы
(Times New Roman шрифты, үлчәме 14 - калын, юл хәрефләр, уртага тигезләү)

Конкурста катнашуга тәкъдим иткән учреждение (учреждениеләр) исеме,
(Times New Roman шрифты, үлчәме 14 - гадәти, юл хәрефләр, уртага тигезләү)

ПРОГРАММА (ПРОЕКТ) ИСЕМЕ
(Times New Roman шрифты, үлчәме 16, калын, баш хәрефләр, уртага тигезләү)

Дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлеше
(Times New Roman шрифты, үлчәме 14 - гадәти, юл хәрефләр, уртага тигезләү)

Ф.И.А.и. (тулысынча), вазыйфасы
(Times New Roman шрифты, үлчәме
14-гадәти, юл хәрефләр,
уң якка тигезләү)

2021